| КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 19 май № 324

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2016 елда авыл җирлегендә урнашкан Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларында физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыру чаралары комплексын раслау турында» 2016 ел, 12 гыйнвар, 1 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2016 елда авыл җирлегендә урнашкан Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларында физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыру чаралары комплексын раслау турында» 2016 ел, 12 гыйнвар, 1 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2013 – 2020 елларга «Мәгарифне үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер карарлары үз көчен югалтуын тану турында» 2016 ел, 27 апрель, 361 нче карарын гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:»;

2016 елда авыл җирлегендә урнашкан Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларында физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыру чаралары комплексында (алга таба – Чаралар комплексы):

2 пунктның «а» пунктчасындагы икенче абзацта «490» саннарын «506» саннарына алмаштырырга;

2 пунктның «а» пунктчасындагы җиденче абзацта «38» саннарын «22» саннарына алмаштырырга;

2 пунктның «г» пунктчасындагы икенче абзацта «33 клуб» сүзләрен «19 клуб» сүзләренә алмаштырырга;

Чаралар комплексына 1 нче кушымта таблицасында:

9 – 11, 28 нче юлларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «Ремонт таләп итеlә торган спорт заллары булган, авыл җирлегендә урнашкан гомуми белем бирү оешмалары саны | барлыгы | 9 | 506 |
| | спорт заллары булган оешмаларның гомуми санынннан % | 10 | 60,7 |
| Спорт заллары ремонтланган, авыл җирлегендә урнашкан гомуми белем бирү оешмалары саны | барлыгы | 11 | 22 |
| Физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен авыл җирлегендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларында төзелгән мәктәп спорт клублары арту | барлыгы | 28 | 19»; |

Чаралар комплексына 2 нче кушымта таблицасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| «Т/б № | Чара исеме | Финанслау күләмнәре, мең сум | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | барлыгы | шул исәптән акча | | | |
| | | | федераль бюджет | Татарстан Республикасы бюджеты | җирле бюджет | бюджеттан тыш акча |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| 1. | Спорт залларын төзәтү | 34 400,3 | 19 400,3 | 15 000* | 0 | 0 |
| | БАРЫСЫ | 34 400,3 | 19 400,3 | 15 000* | 0 | 0 |

* Акча «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы мәгарифен һәм фәнен үстерү» дәүләт программасының «Гомуми белем» бүлекчәсе кысаларында «2016 елга Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законының «Татарстан Республикасы дәүләт (муниципаль) милкенең социаль һәм инженер инфраструктурасына бюджет инвестицияләре һәм капиталь төзәтү» максатчан статьясында күздә тотылды.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков